| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| , Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23 тел. (84362) 46-8-49 | 422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт тел. (84362) 46-8-49 |

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
14.02.2020

КАРАР
№ 5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2012 нче елның 31 нче маенда кабул ителгән 11 нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2009 ел, №432-ФЗ Федераль закон һәм «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2009 ел, №48-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2012 нче елның 31 нче маенда кабул ителгән 11 нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 20.3.пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.2 пунктның 6) 12.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш..

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/ evlashtay адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев